| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

21.06.2019 № 294-р

2019 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49 маддәсенә таянып, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм югарыда аталган законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнарга социаль найм һәм дәүләт торак программалары буенча торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» 2006 елның 23 июнендәге 694 номерлы карары нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану өчен 2019 елга түбәндәге максималь күләмне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь күләме:

1.1.1 ялгыз яшәүче граждан өчен – 718051,62 сум;

1.1.2 ике кешедән торган гаилә өчен – 913883,88 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 1174993,56 сум;

1.1.4.дүрт кешедән торган гаилә өчен – 1566658,08 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 1958322,6 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 2349987,12 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 2741651,64 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 15770,64 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 10035,86 сум;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 8602,17 сум.

2. Әлеге карар үз көченә кергәннән бирле «2018 елга гражданнарның кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен

билгеләү турында» 2018 елның 5 июнендәге 218-р номерлы боерыкны үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 ел, 21 июнь, 294-р номерлы
боерыгына кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2019 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләүне исәпләү**

**1. Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече**

СЖ = НП х РС х РЦ, монда
СЖ – исәп күрсәткече;
НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны;
РЦ - торак урындагы бер квадрат метрның муниципаль берәмлектәге уртача шартларга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урыннарны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар хакыннан артып китми торган уртача исәпләнгән базар бәясе.
1). Ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 33 х 21759,14 = 718051,62 руб.
2). Ике кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 42 х 21759,14 = 913883,88 руб.
3). Өч кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 3 х 21759,14 = 1174993,56 руб.
4). Дүрт кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 4 х 21759,14 = 1566658,08 руб.
5). Биш кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 5 х 21759,14 = 1958322,60 руб.
6). Алты кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 6 х 21759,14 = 2349987,12 руб.
7). Җиде кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 7 х 21759,14 = 2741651,64 руб.

**2. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү**

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$ ) / (0,3 х РС)**, монда

ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;
СЖ – социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече, ул формула буенча билгеләнә:
СЖ = НП х РС х РЦ, монда:

НП –гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ – торак урындагы бер квадрат метрның муниципаль берәмлектәге уртача шартларга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урыннарны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар хакыннан артып китми торган уртача исәпләнгән базар бәясе.

ПС – кредит буенча процент ставкасы бер ай эчендә (унлы вакланма); (Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы бер елга 7,75% , ягъни, 7,75/100/12 айга=0,0065 айга).

КП – кредитның барлык срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (180 айлар саны);

0,7 – кредит суммасының фатир хакына карата нисбәте;

0,3 – кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма keremenә карата нисбәте.

«Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы» КП 18.06.2010 ел, № 124 «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» гы хаты нигезендә, 2019 елның 1 яртыеллыгында Нурлат муниципаль районы буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 21759,14 сум тәшкил итә.

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү**

1). Ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = (0,7x 718051,62 x0,0065):(1 - (1 + ПС) $^{-КП}$):(0,3 x 1) = 15770,64 сум.

2) Ике кешедән торган гаилә өчен:

ПД = (0,7x 913883,88 x0,0065):(1 - (1 + ПС) $^{-КП}$):(0,3 x 2) = 10035,86 сум.

3) Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен:

ПД =(0,7x 1174993,56 x0,0065):(1 - (1 + ПС) $^{-КП}$):(0,3 x 3) = 8602,17 сум.